**Межрегиональные предметные олимпиады КФУ**
**профиль «Татарский язык»**
**заключительный этап**
**2024-2025 учебный год**
**8-9 классы**

**I. “У” хәрефенең [w] авазын белдергән очрагына исем, сыйфат сүз төркеменә караган 10 мисал языгыз.** / Напишите 10 слов (имя существительное, имя прилагательное), в которых буква “у” выражает звук [w]. *(10 баллов. За каждый правильный ответ – 1 балл).*

**II. “Таш” сүзе кергән 5 фразеологизм языгыз, мәгънәләрен аңлатыгыз. /** Напишите 5 фразеологизмов с компонентом “таш” и объясните значение. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла).*

**III. Түбәндәге сүзләрнең татар телендәге синонимнарын табыгыз:** санаторий, парикмахер, бизнесмен, путевка, горизонт, общежитие, километр, рюкзак, аптека, скидка *(10 баллов. За каждый правильный ответ – 1 балл).*

**IV. Өзектә аерып күрсәтелгән сүзләрнең мәгънәсен аңлатыгыз. /** Объясните значение выделенных слов. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла)*

*Безнең әби күрше авылда тора. Беркөнне әни әбиләргә ял итәргә китте.*

*Бөтен өй эше әти белән минем өскә төште. Әни өйдә булганда, мин аңа рәтләп булышмый идем. Эш үземнең җилкәгә төшкәч, әниемнең эше бик күп булганлыгына төшендем һәм, аңа ярдәм итмәвем өчен, үземне бик нык* ***шелтәләдем****.*

*Иртән торабыз. Мин сеңлем Фәүзияне юындырам. Өс, аяк киемнәрен табып бирәм, кайберләрен үзем кидертәм, ә кайберләрен үзенә кияргә кушам.* ***Аксөяк*** *булып үсмәсен әле, үзен-үзе карарга өйрәнсен дим. Аннары форточкаларны ачып, идәнне себерәм.*

*Ул арада әти чәй кайнатып алып керә. Бергәләп утырып чәй эчәбез дә, мин Фәүзияне балалар бакчасына илтеп кайтам. Аннан мәктәпкә китәм. Әти эшкә китә.*

*Мин әтидән иртәрәк кайтканга күрә, аш та пешереп торырга туры килә. Бу эш башта бик авыр тоелды.* ***Чама****ны белми аптырадым.*

*Беркөнне минем төймәм өзелде. Әти тагып бирмәкче иде. Ничек инде, үз кулың була торып, эшеңне оялмыйча әтиеңнән эшләтергә кирәк?!* ***Азапланып*** *булса да үзем тактым. Энә саплый алмый* ***йөдәп*** *беттем. Бер-ике тапкыр*

*бармагыма чәнчеп алдым. Инде тагып бетердем дисәм, кыек тагылган. Башка төймәләрдән бөтенләй читтә тора.*

(А.Алиш “Әни ялга киткәч”).

**V. Бирелгән өзектән дүрт-биш мәгънәле кисәктән торган 5 сүз табып языгыз. /** Найдите в тексте 5 слов, состоящих из 4-5 морфем. *(10 баллов. За каждый правильный ответ по 2 балла)*

Карчыкның соңгы еллардагы гомере шул балаларының кайтып китүләрен көтеп яшәү белән генә уза башлады. Дөрес, моннан ун ел элек, карты үлгәннән соң, балалары карчыкны калага тартып караганнар иде каравын, ләкин Акъәби гомер иткән нигезен ташлап китәргә теләмәде инде. Шушы Юлкотлыда туган ул, үскән ул, шушы Каһарман карт өенә килен булып төшкән, шушында илле биш ел яшәгән, уллар-кызлар үстергән. Шушы Юлкотлы туфрагында аның атасы, анасы, күпме туганнары, яшьли үлгән сабыйлары, гомер иткән карты ята – йә, ничек шуларның барысын да ташлап китәсең?.. Күп торасы да калмагандыр, ят җирнең туфрагына барып ятканчы, шушында үзенең ата-анасы, карты, сабыйлары янында булыр – шулай уйлаган иде карчык ул чакта. Һәм, һичнигә карамастан, хәзергә чаклы ул шушы ниятендә нык торды.

Шулай да карчыкка җиңел түгел иде. Туган туфрак никадәр генә үзенә бәйләмәсен, авыл артындагы канау белән әйләндереп алган зиратта ятучы әрвахлар нихәтле генә якын булмасын, әмма болар гына аның тормышын тутыра, ялгызлыгын җиңеләйтә алмыйлар иде.

(Ә.Еники “Әйтелмәгән васыять” әсәреннән)

**VI. ӘЛЕ, ӘЛЛӘ, ИНДЕ, ХӘТТА, СОҢ кисәкчәләренең үзләре бәйләнгән сүздән алда да, артта да килүен исбатлап, җөмләләр уйлап языгыз. /** Напишите примеры (предложения) с частицами ӘЛЕ, ӘЛЛӘ, ИНДЕ, ХӘТТА, СОҢ, показав, что они могут располагаться и до, и после связанного с ними слов. *(15 баллов. За каждый правильный ответ по 3 балла)*

**VII. Туры сөйләмне кыек сөйләмгә әйләндереп языгыз. /** Переделайте прямую речь в косвенную. *(15 баллов).*

*Кышның беренче кары җир өстенә ак җәймәсен каплауга, без икенче сыйныф укучылары белән тимераякта шуу түгәрәгенә язылырга киттек. Тренер абый янына кердек тә, исәнләшеп:*

*– Без тимераякта шуарга телибез, – дидек.*

*– Димәк, классыгыз белән шуарга өйрәнәсегез килә инде? Ә тимераякларыгыз бармы соң?*

*Без, бер-беребезгә карашып, сүзсез басып торабыз.*

*– Тимераяклар кибеттә кыйммәт тора. Алардан башка түгәрәккә язылып булмый, – диде тренер абый.*

*– Нишләргә соң инде? – диде Наилә, кыюсыз гына. – Без бик теләгән идек...*

*Мин дә:*

*– Ярдәм итегез инде безгә, – дип өстәп куйдым.*

(Д.Гайнетдинова «Без – варислар»)

**VIII. Мирас... Бу сүзне безнең заманда бик еш кулланалар. Без нәрсә генә кулга алсак та, тирә-ягыбызда нәрсә генә күрсәк тә – болар барысы да мирас дип аталырга хаклы.**

**Сез нәрсәләрне буыннан-буынга мирас итеп тапшырып була дип уйлыйсыз? Өзектәге фикергә үз мөнәсәбәтегезне белдереп, 15-20 җөмләдән торган бәйләнешле текст языгыз. Фикерегезне раслап, 2 дән ким булмаган дәлил китерегез.** / Как вы думаете, что можно передать в наследство из поколения в поколение? Напишите сочинение-рассуждение из 15-20 предложений, выражая свое отношение к мысли отрывка. Приведите не менее 2 довода-примера. *(20 баллов)*